ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 031 от « 06 » 03 2018 г.

Район Башлыгының 2015 елның
3 июнендә кабул ителгән
049 нчы санлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 30.07.2010 № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 маддәсе нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 ел, 3 июнь, 049 нчы санлы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмә төзергә вәкаләтле затлар билгеләү исемлеген, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1. маддәсе буенча беркетмәләр төзүне өстәп, тулыландырырга (кушымта нигезендә).

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов

000110

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгының
06.03.2018 ел, 031 нче санлы
карарына кушымта

| Маддәнең номеры | Маддәнең эчтәлеге | җирле үзидәрәнең беркетмә төзү вәкаләте йөкләнгән органы | Вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 2.1. маддәсе | Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты | - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча);<br>-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты юридик бүлеге баш белгече (җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген оештыру буенча);<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты юридик бүлеге әйдәп баручы белгече (шәхси торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм шәхси профилактик чаралар үткәрү инспекторы)<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма Комитеты территориаль бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты инфраструктура бүлеге белгече. |

Муниципаль район Советы
аппараты җитәкчесе В.Н.Фаизов